


Ел башланды һәм татар әдәбиятында олы урын алып торган язучыларнын бер-бер артлы тvгәрәк даталары башланды. Беренче январьда язучы һәм публицист Фатих Әмирханнын тууына - 140, новатор шагыйрь Һади Такташнын тууына 125 ел тулды. Ә 2026 елнын 26 апрелендә татарнын боек шагыйре Габдулла Тукайнын тууына шулай ук 140 ел була.      Мордовиядә туган якташ язучыбыз Һади Такташ (Мохәммәтһади Хәйрулла улы Такташев) туган конен лаеклы каршылау максаты белән берничә тобәкара дистанцион конкурсы игълан ителгән иде. Барысын «Мордовия Республикасы милли мәдәниятен, дәvләт телләрен һәм Мордовия Республикасында башка телләрне саклау һәм vстерv» дәvләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Мордовия Республикасы «Педагогик хезмәткәрләрнен һонәри осталыгын озлексез арттыру vзәге-  «Педагог 13.ру» оештырды. Кон-курста Мордовия Республикасы һәм Россия Федерациясе тобәк-ләре мәгариф оешмаларынын тәр-биячеләре, мәктәпкәчә белем бирv оешмаларында тәрбияләнvчеләр, 1-11 сыйныф укучылары катнашты. Катнашучыларнын гомуми саны - 80 бала. Регионыбыз жинvчеләрен әйтеп китәбез.

«Һади Такташнын әсәрләрен сәнгать-ле уку» номинациясендә Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбе 4 класс укучысы Абдулов Самир «Алсу» поэмасыннан озекне яттан сәнгатьле укып жинvче исемен яулый. Укытучысы - Венера Няим кызы Адикаева.

Шул ук номинация 5-9 сыйныфлылар арасында Ромоданово районы Алтар топ мәктәбе 6нчы сыйныф укучысы Исхакова Мәликә «Әvхәди» шигырен укып жинә. Укытучысы – Венера Галлям кызы Конешева.

Ләмберә районы Кривозерье урта мәктәбе 9 сыйныф укучысы Манеева Амина «Иптәшләр» шигырен матур яттан укып жинvче була. Укытучысы – Луиза Низаметдин кызы Смакаева.

«Боек корәш жырчысы мин» те-масын яктырткан сочинениелар кон-курсы арасында жинvчеләр юк, при-зерлар гына.

Мордовия мәк-тәпләрендә татар теле укытучылары чарадарнын тор-лесен Яна елга кадәр һәм яна 2026 нчы елда да торле-торле чаралар vт-кәрделәр һәм vткәрәләр. Мәсәлән, Дубенка районы Кочкурово урта мәктәбендә Альфия Кетдюс кызы Узбякова Һади Такташ шигырьләрен сәнгатьле яттан уку конкурсын декабрьдә vткәрә һәм жинvчеләре Мусин Абдулла белән Яхеев Айрат тобәкара конкурсында катнашып призерлык урыннарны яулаганнар.

**Н. ХӘЛИЛ**